РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

30.06.2022

№ 563-п

2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм аларны норматив хәлгә китерү муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының "2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм аларны норматив хәлгә китерү муниципаль программасын раслау турында" 2020 елның 21 октябрендәге 1406-п номерлы карары белән расланган, 2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм аларны норматив хәлгә китерү муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспорты таблицасында «Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

Программаны финанслау күләмнәре	2021-2025 елларда Программаны Саба муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финанслауның гомуми күләме 84 749,082 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән: 2021 ел - 16 750,227 мең сум; 2022 ел - 17 098,855 мең сум; 2023 ел - 16 900,000 мең сум; 2024 ел - 17 000,000 мең сум; 2025 ел - 17 000,000 мең сум. Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план

	чорына)Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк. Сакланган акчаларның калган өлешен ел саен юл хәрәкәте куркынычсызлыгы чараларына җибәрергә.

»;

1.2. 3 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«

2021-2025 елларга
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү муниципаль программасының төп чаралары

3 таблица

№ п\п	Чараның атамасы	Башкаручылар (килешү буенча)	Финанслау күләме һәм чыганаклары (мең сумнарда)	Үтәү вакыты
1	Смета документларын эшләү	Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирлекләр башлыклары	Саба муниципаль районы бюджеты, Барлыгы 84749,082, шул исәптән: 2021ел - 16 750,227; 2022 ел - 17 098,855; 2023 ел - 16 900,000; 2024 ел - 17 000,000; 2025 ел - 17 000,000, әлеге Программаның 4 таблицасында күрсәтелгән финанс чараларын бүлү нигезендә	Агымдагы елның апрель - март айлары
2	Смета документларын тикшерү	"Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының бердәм заказчысы хезмәте» МУП, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Саба районы территориаль бүлеге		тикшерүгә бирелгән көннән башлап 1 атна дәвамында
3	Төзекләндерү эшләрен башкару	Ачык аукцион нәтиҗәләре буенча электрон сатуларда откан подрядчы оешма		контрактта күрсәтелгән сроклар
4	Башкарыла торган эшләрнең сыйфатын техник күзәтү һәм тикшереп тору	«Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының бердәм заказчысы хезмәте» МУП		эшләр эшләнү дәвамында
5	Башкарылган эшләрне кабул итү һәм объектны	Заказ бирүче - (объектның баланс тотучысы),		төзекләндерү эшләрен төгәлләү буенча

	файдалануга тапшыру	Заказ бирүче-төзүче - "ТР Саба муниципаль районы Башкарма комитетының бердәм заказчысы хезмәте" МУП		

»;

1.3. 4 таблицаны әлеге карарга 1 кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы Э.Д. Рамазановка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Башкарма комитетының
2022 елның 30 июнендәге 563-п номерлы
карарына 1 кушымта

4 таблица

2021-2025 елларда җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзекләндерүгә юл фондының финанс чараларын бүлү

№	Җирлекләр исеме	Акчаларны еллар буенча бүлү (мең сум)				
		2021	2022	2023	2024	2025
1.	Саба шәһәр җирлеге	4 563,420	3 306,435			3400,000
2.	Арташ авыл җирлеге	1 871,020				3400,000
3.	Олы Кибәче авыл җирлеге		608,110			
4.	Олы Нырты авыл җирлеге	1 152,120	2 229,460		3400,000	
5.	Олы Шыңар авыл җирлеге	1 580,180				
6.	Корсабаш авыл җирлеге			3380,000		
7.	Югары Симет авыл җирлеге					
8.	Явлаштау авыл җирлеге			3380,000		
9.	Эзмә авыл җирлеге	148,840				
10.	Иштуган авыл җирлеге			3380,000		
11.	Килдебәк авыл җирлеге	2 734,780				
12.	Түбән Шытсу авыл җирлеге			3380,000		
13.	Мишә авыл җирлеге	943,250	363,350			3400,000
14.	Мичән авыл җирлеге		2 138,440	3380,000		
15.	Сатыш авыл җирлеге				3400,000	
16.	Иске Икшермә авыл җирлеге		658,900		3400,000	
17.	Тимершык авыл җирлеге	1 571,340	1 658,660			3400,000
18.	Шекше авыл җирлеге				3400,000	
19.	Юлбат авыл җирлеге				3400,000	
20.	Шәмәрдән авыл җирлеге	2 185,277	6 135,500			3400,000
	БАРЛЫГЫ:	**16 750,227**	**17 098,855**	**16 900,000**	**17 000,000**	**17 000,000**